## Арча муниципаль район башлыгы А.Ә.Назиров чыгышы

**Хөрмәтле депутатлар, чакырылган иптәшләр!**
**Хөрмәтле Ринат Зинурович, Альберт Харисович!**

Бүген без Сезнең белән сәяси вакыйгаларга, юбилей даталарына бай булган 2010 елга йомгак ясыйбыз. Шул ук вакытта, мөгаен, ул үзенең үтә салкын кышы, моңарчы күрелмәгән корылык алып килгән эссе җәе белән дә истә калыр!

Дөрестән дә, ул республика, район тормышында өстәмә борчу-мәшәкатьләр алып килде, нык оешканлык таләп итте, барыбыз өчен дә чын сынау елы булды.

Бүген инде Арча районы халкы, сайланган депутатлар, җитәкчеләр корпусы бу табигать һәм заман сынауларын уңышлы үтте, дип әйтергә нигез бар.

Без узган авыр елны таркаулыкка, күңел төшенкелегенә бирелмичә, барлык хезмәт коллективларын саклап калып, күпчелек җитештерү тармакларында хәтта моңарчы ирешелгән җитештерү һәм хезмәт хакы күрсәткечләрен арттыруга ирешә алдык.

### Авыл хуҗалыгы

Әлбәттә, үтә көйсез табигать шартларыннан район экономикасының төп тармагы булган авыл хуҗалыгы зур зыян күрде. Суыклар аркасында көзге культураларның яртысын югалттык, язгы-җәйге корылык уңышка булган барлык өметләрне өзде. Үсемлекләрнең актив үсеш чоры май, июнь, июль айларында барлыгы 31 мм явым-төшем булды, бу уртача

еллык нормадан 5 тапкыр кимрәк. 35-40°С эсселектән барлык яшеллек тамырдан көйде.

Нәтиҗәдә үсемлекчелек тармагыннан тулаем продукция 390 млн. сумлык җыелып, 2009 ел белән чагыштырганда 26% кына булды, шулай итеп корылыктан күргән зыян млрд. сумнар белән исәпләнә.

Бу шартларда җитәрлек күләмдә терлек азыгы туплау һәм кирәгенчә сыйфатлы орлык материалы әзерләү мөмкин булмады.

Шуңа күрә җәйге-көзге чорда чит өлкәләрдә терлек азыгы хәзерләүгә, фураж запасы туплауга зур игътибар бирелде.

Бу корылык уңай килгән елларда терлек азыгын күпләп туплап, страховой запас булдыру кирәклеген ачык күрсәтте. Алдагы елдан терлек азыгы калдыклары булган Кырлай, Курса хуҗалыклары бүген үзләрен иркен хис итәләр.

Соңгы 3 елда без агрофирмаларда мөгезле эре терлек санын 5800 башка арттыра алдык, терлекчелек продукциясе җитештерү дә елдан ел арта. Отчет елында терлек саны 2300 башка артып, сөт җитештерү 8%, ит – 1% артты. Районның бу күрсәткечләренә зур өлеш керткән “Ак Барс Агро”, “Вамин-Арча”, “Игенче”, “Кырлай” агрофирмаларын, терлекчеләрен, аларның җитәкчеләрен мактап телгә аласы килә.

Бүген безнең алда кышлатуның иң җаваплы, иң авыр 3 ае тора. **Баш саннарының, продукция җитештерүнең кимүенә юл куймыйча кышлатуны уңышлы тәмамлау – безнең төп бурыч.**

Нәкъ менә шундый шарт белән, безгә зур күләмдә хөкүмәт ярдәме күрсәтелде. Искә төшерү зыян итмәс, районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре 2010 ел ахырында гына да корылыктан килгән зыян өчен 45 млн., терлек азыгы хәзерләүгә 50 млн., терлекләрнең баш санын

саклап калуга 37 млн., ашлама һәм ягулык-майлау материалларына 49 млн. сум акча алдылар. Барлыгы ел дәвамында район буенча хуҗалыклар 1 млрд. 550 млн. 592 мең сум күләмендә акчалата ярдәм алдылар.

Шуның өстенә кредитлар озынайтылды (пролонгация), түләнгән процентларга субсидия бирелә.

Дәүләт авыр елны безне ярдәмсез калдырды дип әйтә алабызмы? Минемчә юк! Калганы инде үзебездән тора! Авыл хуҗалыгында хәлне тасвирлаганда бүгенге көндәге кыенлыклар белән беррәттән уңай үзгәрешләрне дә күрсәтергә кирәк. Шуның иң куанычлысы – бүген авыл хуҗалыгы продукциясенә сорау зур, бәяләр дә начар түгел. Сөтнең 1 литрын 18-20 сумга, тере үлчәүдә ит бәясен 100 сумга сату безнең күптәнге хыял иде, ул да тормышка ашып килә дисәк, ялган булмас.

Авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче дүрт меңнән артык кешенең елдан-ел хезмәт хаклары артуы матур күренеш. Алдагы ел белән чагыштырганда отчет елында ул 6% ка үсеп 7332 сум тәшкил итте.

Авыл хуҗалыгы буенча кыска гына анализны тәмамлап, бу тармакның якын киләчәктәге төп проблемасы турында әйтәсе килә. Ул былтыргы корылык та, быелгы авыр кышлату да, техника җитмәү дә, сатып алу бәяләре һәм акча кытлыгы да түгел, ә кадрлар – эшче көчләр проблемасы булачак.

Бүген үк инде белгечләр, урта буын җитәкчеләр, шофер, трактористлар, терлекчеләр җитмәү сизелә. Бер үк вакытта күп җирдә “авыл кешесенә” эш юк дибез.

Капма-каршы хәл!?

Халык эшләргә эш юк ди! Күп җитәкчеләр эшләргә кеше җитми дип белдерә! Миңа калса, эш тә күп, эшләргә кеше дә әлегә бар! Монда төп

сәбәп – авыл хуҗалыгында үзгәрешләрдән соң җитәкчелекнең, яңа хуҗаларның хезмәт коллективларында, эшче көчләр белән аңлаешлы мөнәсәбәттә булмавында.

**Бүгенге көндә кадрлар резервы булдыру, эшне планлы, системалы алып бару авыл хуҗалыгы идарәсенең, агрофирма җитәкчеләренең төп бурычы!** Кадрлар барсын да хәл итә дигән әйтем бүген дә бик урынлы!

Соңгы елларда илдә, республикада азык-төлек программасын үтәү, авыл халкын эш белән тәэмин итү максатында фермер, шәхси крестьян хуҗалыкларына игътибар арта. Моңарчы 80 ел дәвамында аларга дәүләт тарафыннан тиешле ярдәм булмады, киресенчә авыл җирендә эшмәкәрлек төрлечә кысылды, кыерсытылды.

Шуңа да карамастан бүгенге көндә дә районда ит-сөтнең 30%, бәрәңгенең 60%, яшелчәләрнең 100% фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар җитештерә!

Хәзерге вакытта алар берничә федераль һәм региональ программалар буенча дәүләттән ярдәм ала.

Иң зурысы һәм отышлысы, әлбәттә, ташламалы кредитлар программасы. 4 ел эчендә районда бу мөмкинлектән 2735 хуҗалык файдаланды, ягъни барлык эшләүче хуҗалыкларның 1/3 (өчтән бере), аларның процентларын түләүгә дәүләттән 62 млн. субсидия алынды. **Әлеге программа дәвам итә һәм агымдагы елда бу эшне активлаштырырга кирәк, хәзер безнең авыл халкының күпчелеге кредитлар белән эш итәргә өйрәнде инде.**

Шәхси хуҗалыклар үсешенә тәкъдим ителгән “Үз эшеңне булдыру” программасы да уңай йогынты ясый. 2 ел эчендә районда 445 кеше 58800 әр

сум субсидия алып үз эшен башлап җибәрде, аларның күбесе авыл хуҗалыгы белән бәйләнгән.

Бу юнәлештә эш быел да дәвам итәчәк. Бу ярдәм үз эшләрен оештыра алып, өстәмә эш урыннары булдыра алырлык кешеләргә вакытында барып җитәргә тиеш.

Узган ел, авыл халкы терлекләрен азык белән тәэмин итүдә күрсәтелгән ярдәм өчен республика җитәкчелегенә бик рәхмәтле. Барлыгы 23,5 млн. сум акча алынып, халыкка 4200 тоннадан артык фураж бирелде, шуның 2600 тоннасы тиз арада чит регионнардан кайтарылды. Читтән өстәмә рәвештә тупас азыклар кайтару вакытында, тиешле югарылыкта оештырылды.

Барлык бу күрелгән чаралар, учет һәм аңлату эше шәхси хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын узган елгы дәрәҗәдә саклап калырга, аз гына арттырырга да мөмкинлек бирде. (Слайд – поголовье скота в ЛПХ в 2010-2011гг.).

**Бу мөһим эш бүгенге көндә дә авыл җирлеге башлыкларының, авыл хуҗалыгы идарәсенең, район советы башкарма комитетының даими контролендә тора.**

Отчет елында республика авыл хуҗалыгы министрлыгы тәкъдиме белән тагын бер өметле һәм бик кызыклы программа тормышка ашырыла башлады. Бу “Гаилә фермалары төзү”. Фермер яки шәхси хуҗалык 24 баш сыер яки 40 баш симертү терлегенә исәпләнгән ферма төзесә, дәүләттән моның өчен 500 меңнән 1 млн. сумга кадәр ярдәм күрсәтелә.

Бүген районда шул тәртиптә эшләргә 25 гаилә теләк белдерде һәм, әлбәттә, без аларга киләчәктә районнан да ярдәм итү мөмкинлеген эзләячәкбез.

**Район башкарма комитеты, аның бүлекләре, җирлек башлыклары ягыннан авыл кешесенә җир бүлеп бирү, терлекләрне азык белән тәэмин итү, кредитлар алу, техника һәм ветеринария хезмәте белән тәэмин итү буенча һәрдаим ярдәм күрсәтелергә тиеш.** Без райондагы 160 өч һәм күбрәк сыер асраучы шәхси хуҗалыкларны алдагы 2 ел эчендә саву аппаратлары белән тәэмин итү бурычын куйдык, һәм бу эшне башлап җибәрдек.

Нигә без соңгы вакытта авыл җирендә кечкенә хуҗалык итү төрләре турында күп сөйләшәбез? Чөнки бу меңнәрчә кешеләрнең яшәү рәвеше, чикләнмәгән мөмкинлекләр юнәлеше, ниһаять бу безнең авылларның ата-бабадан калган нигезе, димәк, авылларның киләчәге!

Авыл хуҗалыгында төп максат – һәр хуҗалыкта сөрүлек җирләренә 1 гектарына исәпләгәндә кимендә 15 мең сумлык продукция сатып, аның рентабельле , файдага эшләвен тәэмин итү.

## Сәнәгать

Район экономикасының башка тармаклары да 2010 елның авыр булуына карамастан сизелерлек үсеш белән тәмамладылар (слайд №__).

2010 елда гомуми җитештерү, хезмәт күрсәтү 5 млрд. 264 млн. сумга җитеп, 2009 ел белән чагыштырганда үсеш 3,4% тәшкил итте. Бу җан башына исәпләгәндә керем 102 мең сум дигән сүз.

Районда иң зур сәнәгать оешмаларыннан саналган – АСПК һәм Арча сөт комбинаты үзләренең кризиска кадәр булган күләмдә җитештерүне тәэмин иттеләр.

Узган ел белән чагыштырганда җитештерү күрсәткечләрен шактый арттырган ОАО “Татавтодор”, ООО “Круг-Агро”, ООО “Энергосервис”, “Газ-сервис”, “Водоканал-Сервис”, ГБУ “Арчалес”, РУЭС, ООО “Жилкомбытсервис” коллективларын аерым атап китәсем килә. Шунысы

куанычлы – җитештерү күләменең үсүе күп оешмаларда өстәмә эш урыннары булдыру, уртача хезмәт хакының артуы белән бәйләнеп бара.

Кызганычка каршы, район буенча тулаем күренешне бозган, алдагы елларда ирешкән күрсәткечләрен киметкән берничә оешма да бар. Алар слайдта ачык күренә.

Һәрбер оешма җитәкчесе үз эшенә тәнкыйть күзлегеннән карап, җитешсезлекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрергә бурычлы. Без бик кызыклы, ләкин кырыс заманда яшибез, алга карап фикер йөрткән, алга барган кеше генә уңышка ирешә. Урында таптанган яки артка тәгәрәгәннең урынын башкалар аласына шик юк.

## Төзелеш, юллар хуҗалыгы һәм транспорт

Районның төзелеш оешмалары отчет елында 1 млрд. 965 млн. сумлык эш башкардылар, бу алдагы ел белән чагыштырганда 34% ка күбрәк. Төрле чыганаклардан финансланган 130 шәхси йорт файдалануга тапшырылды. Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү Программасы буенча эш аеруча актив алып барылды. Бу программа буенча төп эш күләме быелга планлаштырыла. Төзелеш эшләре тулы көченә бара һәм ветераннарыбызның зур күпчелеге Җиңү бәйрәменә кадәр фатирлы булачак!

Елның киеренке булуына карамастан районда көнкүреш, мәгариф, мәдәният объектларын төзү-төзекләндерү буенча да зур күләмдә эш башкарылды. Арча район мәдәният йорты реконструкциясе, Яңа Кенәр мәктәбенә янкорма төзү, 1 номерлы Арча урта мәктәбенең өстәмә бинасын төзүгә зур чыгымнар тотылды. 7 күп квартиралы йортка капиталь төзекләндерү ясалды.

Районда 2010–2015 елларга энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча муниципаль программа эшләнде һәм расланды. Бюджет учреждениеләре 2015 елга барлык энергия ресурслары куллануны кимендә 15 процентка (ел саен 3 процент) киметергә тиешләр, Коммуналь өлкәдә су, җылылык, электр белән тәэмин итү системаларында исәп үзәкләре урнаштыру программасы эшләнде. Шәһәрнең барлык күп фатирлы торак йортларында гомуми йорт һәм фатирлар буенча су, электр энергиясе, барлык социаль–мәдәни әһәмияттәге объектларда җылылык энергиясе исәпләү счетчиклары куелды.

Болардан тыш районда күп фатирлы йортларны тулысынча 2 контурлы аерым газ казаннарын җылылык белән тәэмин итү программасы эшләнде. 2009 елда - 97, 2010 елда - 530 фатир аерым җылытуга күчерелде. 2011 елда 453 фатирда аерым казаннар куеп бу эшне тулысынча төгәлләү планлаштырыла.

2011 елда тузган торакны яңартуга игътибар биреләчәк, аңа 16 млн. сумнан артык акча бүленү каралган. Шулай ук Арча шәһәрендә 140 урынлы 1 балалар бакчасы, 1 нче номерлы мәктәпнең спортзалын, пожар депосын файдалануга тапшыру күздә тотыла.

Отчет елында зур күләмдә юл төзү эшләре башкарылуга карамастан, районда яхшы сыйфатлы юллар проблемасы кала бирә. Әлегә районның 54 авылына асфальт юл килмәгән, бу авылларда 9 меңнән артык халык яши.

2010 елда планда 313,5 млн. сумлык каралып, 452 млн. сумлык юл төзү һәм ремонт эшләре башкарылды, агымдагы елда 390 млн. сумлык эшләү планлаштырыла.

Яхшы сыйфатлы юллар булдыру район экономикасын ныгытуга, халыкка, мәктәпләргә транспорт хезмәте күрсәтүне арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Былтыргы коры һәм эссе җәй су чыганакларына, халыкны, оешмаларны су белән тәэмин итүгә аерым игътибар сорады. Бу мәсьәләнең аеруча мөһим икәнлеген тагын бер кат искә төшерде, су кытлыгы нык сизелде. Арча шәһәрен су белән тулысынча тәэмин итү максатында ООО “Водоканал-Сервис” көче белән гомуми су үткәргеч системага өстәмә рәвештә 9 артскважина, 1 чишмә тоташтырылды.

Арча шәһәрен су белән тәэмин итүнең кискенлеген искә алып республика хөкүмәте оператив рәвештә 9,6 млн. күләмендә ярдәм күрсәтте. Нәтиҗәдә ООО “Вика” көче белән Казиле авылындагы скважинадан су үткәргеч эшләнеп, шәһәр су системасына тәүлегенә өстәмә 1500 $м^3$ су бирелә башлады.

## Сәүдә һәм эшмәкәрлек

Соңгы елларда районыбызда, сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка хезмәт күрсәтү тармаклары нык үсеш алды. Моның төп сәбәпләре районда кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсешенә шартлар тудыру булса, икенче яктан – халыкның сатып алу мөмкинлеге арту. Елдан-ел Арча шәһәрендә, авылларда заманча төзелгән һәм җиһазландырылган сәүдә нокталары барлыкка килә. Алардагы сәүдә итүнең сыйфатын, товар ассортиментын, әлбәттә, элеккеге сельпо кибетләре белән чагыштыру җир белән күк арасы.

Отчет елында товар әйләнеше 13% ка үсеп 2 млрд. 111 млн. га җитте. Районның төп сәүдә берләшмәләре ООО Фирма “Круг” – барлык район

товар әйләнешенең 23%, ООО “Тайд-Фойл” – 15%, Арча сәүдә идарәсе – 14% - елны зур үсеш белән төгәлләделәр. Сәүдә әйләнешенең кискен үсүенә үзебездә күпләп сату складлары булу, былтыр Арчада, Казанда еш үткәрелгән ярминкәләр, бәйрәм чаралары һәм иң мөһиме уңай бәяләр конъюнктурасы булдыра алу сәбәп булды. Игътибар итсәгез, Арчада бәяләр Казандагыдан түбәнрәк, ә авылларда исә Арчадан да түбән булу очраклары бар. Бу кече эшмәкәрлек үсешенең, сәүдәдә конкурентлык факторының көчле булуының уңай нәтиҗәсе.

Сәүдә өлкәсендә бүген ачык күренеп торган төп кимчелек – күпчелек кадрларның әзерлексез булуы һәм аларның еш алышынуы.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов күрсәтмәсе буенча дәүләт һәм муниципаль заказчылар товарлар (эшләр, хезмәтләр) кайтару өчен заказларны электрон мәйданчыгында электрон рәвештә ачык аукцион үткәрү юлы белән урнаштырырга тиешләр. 2010 елда районда электрон рәвештә 18 ачык аукцион үткәрелде. Бу ел дәвамында халык алдында үткәрелгән сатуларның 13 процентын тәшкил итә.

Бүгенге көндә районның 20 оешмасы электрон сәүдә мәйданчыгында теркәлү үтеп, актив эшчәнлек алып бара.

2011 елның 1 гыйнварыннан Интернет челтәрендә заказлар урнаштыру турында мәгълүмат бирү өчен Россия Федерациясе буенча рәсми сайт эшли. Арча район башкарма комитеты әлеге сайтта районның муниципаль заказчылары өчен сәүдә үткәрүдә вәкаләтле орган буларак теркәлгән.

Киләчәктә районның социаль-экономик үсешен кече һәм урта бизнес, эшмәкәрлектән башка күз алдына китереп булмый. Бүгенге көндә районда 334 кече предприятие, 1187 шәхси эшмәкәр теркәлгән. Алар

халык хуҗалыгының төрле тармакларында уңышлы эшләп киләләр. Бигрәк тә сәүдә, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә аларның өлеше зур. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, халыктан җыю һәм эшкәртү белән шөгыльләнүчеләрнең артуы безнең район өчен бигрәк тә актуаль һәм куанычлы. Шундыйлардан Наласа авылында ООО "Натурпродукт", Кырлайда ООО "Кырлай-хлеб" уңышлы эшләп китте. Кушлавычта сөт эшкәртү цехы ачылу алдында. Шулай да районыбызда җитештерү өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек тулысынча эшли дип әйтеп булмый.

Районда яңа предприятиеләр ачылу – ул яңа эш урыннары барлыкка килү дигән сүз. Шуңа да киләчәктә район халкын эш белән тәэмин итүдә эшмәкәрләргә зур өметләр баглыйбыз. Кече предприятиеләрдә эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакы 2010 елда 10541 сум булып, алдагы ел белән чагыштырганда 11% ка үсте, район бюджетына алардан салым керемнәре барлык керемнең 25% тәшкил итте.

Район башкарма комитеты, җирлек башлыклары урыннарда халыкның эшмәкәрлек активлыгын арттыруга, бигрәк тә җитештерүче кече предприятиеләр булдыруга игътибарлы һәм ярдәмле булырга тиешләр. Шул максатта районда оешкан эшмәкәрләр советының эшен нык активлаштырасы бар!

## Хезмәт һәм мәшгульлек

2010 елга халык санын алу нәтиҗәләре буенча районыбызда 51691 кеше яши. Шуларның 27 меңе эш яшендәге кешеләр.

Отчет елы дәвамында эш урыннарын саклау, хезмәт хакы күләменә һәм аны вакытында түләүгә зур игътибар бирелде. Нәтиҗәдә барлык тармакларда да уртача айлык хезмәт хакының артуы күзәтелә. Алдагы ел

белән чагыштырганда авыл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәт хакының үсеше 6%, сәнәгатьтә - 4%, төзелеш тармагында – 20%, сәүдәдә - 17% тәшкил итте.

Гомумән район буенча 2010 елда уртача айлык хезмәт хакы 9815 сум булды, ягъни 7% ка үсте. Төрле оешмаларда бу күрсәткеч, әлбәттә, төрлечә. "Татавтодор" ның Арча филиалы, ОАО "Арскнефтепродукт", РУЭС, ООО "Шанс" үзләренең эшчеләренә 15000 һәм аннан да күбрәк хезмәт хакы түләделәр. Шул ук вакытта 7000 сумнан да түбәнрәк, ягъни минималь куллану бюджетыннан да ким түләгән оешма-предприятиеләр дә юк түгел (слайд____).

Соңгы еллардагы чын инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, район оешмаларының экономик мөмкинлекләрен күз алдында тотып, **без быел уртача хезмәт хакын 12% ка арттырып, 10506 сумга җиткерү максатын куябыз!**

Районда хезмәтне саклау, техника куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләренә дә зур әһәмият бирелә. "2010–2012 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту программасы" эшли, шуның нигезендә кешеләребезнең иминлеген саклау буенча бик күп чаралар уздырыла. Районда хезмәтне саклау, техника куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында смотр–конкурс үткәрелде, анда "Северный" хуҗалыгы җиңүче дип табылды. Әлеге мөһим мәсьәлә киләчәктә дә ныклы контрольдә булачак.

Халыкны эш белән тәэмин итү, эшсезлек дәрәҗәсен киметү буенча районда системалы эш алып барыла. Отчет елы башында мәшгульлек үзәгендә 319 кеше теркәлгән иде, ел ахырына аларның саны 210 калды.

Эш эзләп тиешле органнарга мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе кризиска каршы чаралар программасы нигезендә төрле оешмаларга, җәмәгать эшләренә урнаштырылды. Барысы 94 оешма белән 239 килешү төзелде.

Программаның башка юнәлешләре – укыту, стажировка, читкә җибәреп эшләтү, үз эшеңне булдыру буенча да актив эш алып барылды. Нәтиҗәдә анда катнашучылар федераль бюджеттан 43 млн. сумлык өстәмә ярдәм алдылар. Армиядән кайткан егетләргә, инвалидларга, тәрбиягә бала алган гаиләләргә аерым игътибар бирелде.

**Агымдагы елда да бу эшләр дәвам ителәчәк, районның һәр кешесе, бигрәк тә авыр тормыш хәленә калганнары безнең игътибардан читтә калырга тиеш түгел!**

## Экология

Районда экологик хәлне яхшырту һәм калдыклар белән эш итү системасын камилләштерү максатларында Арча шәһәре муниципаль берәмлеген санитар чистартуның генераль схемасы эшләнде. 2010 елда бюджет учреждениеләренә тирә–як мөхитне пычраткан өчен лимиттан тыш түләүләр исәпләүгә юл куймау максатында шәһәр һәм районның 219 бюджет учреждениесенә экологик документлар эшләнде. Яңа Ашыт авылы янындагы гидротехник корылма 8 млн. сумга ныклап төзекләндерелде.

Бүген сезнең игътибарга “Арча муниципаль районы территориясендә 2011–2015 елларга кадәрге чорга экология куркынычсызлыгын тәэмин итү” дигән муниципаль программа тәкъдим ителәчәк.

## Мәгълүмат–коммуникация технологияләре

Мәгълүмат–коммуникация технологияләренең бик тиз үсеш алуы киләчәктә без аларны эштә генә түгел, көндәлек тормышыбызда да читләтеп үтә алмавыбыз турында сөйли. Һәм без, муниципаль власть органнары, Интернетка һәм башка ресурсларга керү юлы бирүче оешмалар белән бергә үз көчебезне Арча муниципаль районында, аеруча авыл җирендә мәгълүмат–коммуникация технологияләрен тагын да үстерүгә юнәлтергә тиешбез.

Соңгы елларда мәгълүмат–коммуникация технологияләрен муниципаль идарәдә куллану өлкәсендә алга китеш бар. Район территориясендә дәүләт һәм муниципаль власть органнарының үзара нәтиҗәле эшләвен оештыру буенча эшчәнлек кысаларында телекоммуникацияләрнең бердәм дәүләт системасы ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы, республиканың дәүләт власте органнары белән видеоконференция элемтәсе һ.б. төзелде.

Районда мәгълүмат–коммуникация технологияләрен тагын да үстерү максатларында Арча район Советының 4нче утырышында “2011–2013 елларга Арча муниципаль районында җирле үзидарә органнарын мәгълүматлаштыру” программасы кабул ителде.

Мәгълүмат–коммуникация технологияләре турында сөйләгәндә мәгариф турында да онытырга ярамый. Беренче компьютерлар безнең районга Татарстан Президенты программасы буенча 2000 елдан кайтарыла башлады, шуның нәтиҗәсендә барлык мәктәпләр заман техникасы белән җиһазландырылды. Компьютерлар паркын яңарту максатларында “Мәктәптә компьютер” программасы буенча 2010 елда яңа, бүгенге көн таләпләренә җавап бирә торган 210 компьютер кайтты.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнехановның “Укытучыга компьютер” программасы ярдәмендә районыбызның 440 укытучысы ноутбуклар алды. Бүгенге көндә барлык төп һәм урта мәктәпләр Интернетка тоташтырылган, аларның үз сайтлары бар. 2010 елгы уку елыннан “Татарстан Республикасы электрон мәгарифе” порталында укытучылары ноутбук алган мәктәпләрдә электрон журналлар алып барыла.

## Мәгариф

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан **Укытучы елы** дип игълан ителгән 2010 ел мәгариф өлкәсенә ярдәм итү, укытучы хезмәтенә игътибарлы һәм ихтирамлы, тиешле бәя бирү елы булды.

Узган елда мәгариф системасын финанслау күләме 351 млн. сум яки гомуми бюджетның 58 процентын тәшкил итте. Капиталь һәм агымдагы ремонтка район бюджетыннан 3 млн. сум бирелде, өстәмә республика бюджеты хисабына 14 мәгариф учреждениесендә янгынга каршы чаралар үткәрелде. Яңа Кенәр урта мәктәбендә 240 укучыга исәпләнгән янкорма сафка басты. Яңача социаль-икътисади шартларда мәгариф өлкәсен үзгәртеп кору тагын да актуальләшә.

Узган уку елы йомгаклары буенча укучыларның өлгереше — 99,9 процент, белем бирү сыйфаты 56 процент тәшкил итте, бу мәктәп коллективларының сыйфатлы белем бирүдә максатчан эшләвен күрсәтә.

Профильле белем бирү – белем бирүнең сыйфатын арттыручы юнәлешләрнең берсе. Барлык 25 урта мәктәптә автокласслар ачылды һәм алар уңышлы гына эшлиләр, “В” һәм “С” категорияле шоферлар

әзерлиләр, ә ел башыннан автокласслар базасында “Тракторист–машинист” һөнәрен алу буенча да укулар башланып китте.

“Мәгариф” дигән илкүләм проект белем бирү өлкәсен камилләштерүгә зур этәргеч булды. 3 ел эчендә районның 6 гомумбелем учреждениесе “миллион”га ия булды. Бүгенге көндә алар сыйфатлы белем бирүче ресурс үзәкләре булып тора. 20 мәктәп 13,5 млн. сумлык укыту–күрсәтмә һәм лаборатория җиһазлары белән тәэмин ителде. Хәзерге вакытта проект буенча бирелгән 11 мәктәп автобусында 610 укучы йөртелә, җирле бюджеттан финансланган тагын 4 мәктәп маршруты ачылды. Барлык мәктәпләр дә Интернет челтәренә тоташтырылды. Иң яхшы 29 укытучы 100 мең сумлык премиягә ия булды.

Мәгариф системасының үсеше күпмедер дәрәҗәдә мәктәпкәчә белем бирү үсеше белән бәйле. Районда үткән елда 58 мәктәпкәчә учреждение эшләде. Балалар бакчаларына чират район буенча 550 бала тәшкил итә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен Укучылар сараенда һәм сәнгать мәктәбендә студияләр ачылды, 7 гаилә балалар бакчасы оешты, быел Арча шәһәренең Бәширов урамында 140 урынлы балалар бакчасы төзелеп, файдалануга тапшырылачак.

Бердәм тариф челтәре буенча педагогларның уртача хезмәт хакы 8345 сум тәшкил итә иде. 1 сентябрьдән кертелгән хезмәт хакын яңача түләү системасы авылларда уртача хезмәт хакын 11,9 мең сумга, ә шәһәрдә 13,5 мең сумга кадәр арттырырга мөмкинлек бирде.

***Мәгариф өлкәсендә 2011 елга бурычлар:***

- төп бурычларның берсе - мәгарифне укучыларның, әти-әниләрнең, җәмгыятьнең, дәүләтнең таләпләренә җавап бирә алырлык югары дәрәҗәгә үстерү.

- алдагы елларда эшчәнлекнең төп юнәлешләре "Безнең яңа мәктәп" ("Наша новая школа") һәм "2010-2015 елларга мәгариф үсеше стратегиясе" программасы бурычларына тәңгәл килергә тиеш:

1) мәктәпкәчә учреждениеләренә электрон чират булдыру;

2) башлангыч гомуми белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын кертүне тәэмин итү;

3) мәгарифтә билге кую системасын модернизацияләү, педагогик хезмәткәрләрнең эшчәнлеге сыйфатына бәйсез бәя бирү системасын булдыру;

4) "Татарстан Республикасының электрон мәктәбе" мәгълүмати-белем бирүче системасын кертүне тәэмин итү;

5) туган тел һәм инглиз телен сыйфатлы итеп укытуны тәэмин итү;

6) сәләтле балалар белән эшне дәвам итү;

7) укытучыларның квалификациясен күтәрүнең яңа системасын кертү;

8) мәгариф учреждениеләрендә сәламәтлек саклау эшчәнлеген үстерү буенча өстәмә чаралар күрү.

## Сәламәтлек саклау

Сәламәтлек саклау эшчәнлегенең мөһим тармакларының берсе булып поликлиникада, амбулаторияләрдә һәм стационарда беренчел табиби-санитария, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү тора. Барлык төр

медицина эшчәнлеге дә лицензияләнде, бу исә үз чиратында дәвалау учреждениеләрен һәм 287 койкага исәпләнгән фондны саклап калырга ярдәм итте. Дәүләт гарантияләре программасы 105 процентка үтәлгән. Ел дәвамында стационарда 9,5 мең авыру дәваланган, поликлиникага 519,5 мең авыру килгән, ашыгыч медицина ярдәме бригадасы 16 мең чакыруга барган.

“Сәламәтлек” илкүләм проектын тормышка ашыруга 17,6 млн.сум акча юнәлтелде. Районның медицина персоналы тарафыннан бушка 340 мең сум күләмендә теш протезлары куелды, федераль һәм региональ дәрәҗәдәге инвалидларны дарулар белән тәэмин итү программасы буенча 29 млн. сумлык 36 мең төрдәге дару җибәрелде, 3 яшькә кадәр балалар 4 млн. сумнан артык суммада сөт ризыклары белән бушка тәэмин ителде.

Бөек Җиңүнең юбилей елында табиблар барлык Бөек Ватан сугышы ветераннарына, сугышта катнашучыларның тол хатыннарына, тыл хезмәтчәннәренә диспансеризация тикшерүе үткәрделәр.

Районның демографик хәлен яхшыртуда да сәламәтлек учреждениеләренең роле зур. Бүгенге көндә районда үлгән кешеләр саны чагыштырмача туган балалар саныннан һаман да югарырак. Мәсәлән, 2010 елда 642 бала дөньяга килсә, үлүчеләр саны – 737.

Хисап тоткан чорда сәламәтлек саклауның матди-техник базасын ныгыту буенча эш дәвам итте. Район бюджеты хисабына 17 млн.сумлык медицина транспорты һәм җиһазлары кайтарылды, районара травматология һәм онкология үзәкләрен оештыру буенча эш дәвам итә.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә уртача хезмәт хакы 9124 сум тәшкил итә, 1 мең кешегә 1,4 табиб туры килә.

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, актив тормыш эшчәнлеген арттыру максатыннан 2011-2015 елларга муниципаль программа кабул ителде.

Халыкның сәламәтлеге торышы районның социаль үсешенең индикаторы булып тора. Шуңа күрә сәламәтлек саклау өлкәсендә ***2011 елда түбәндәге бурычларны хәл итү мөһим булырга тиеш***:

- кешеләрнең гомерләрен озынайту максатыннан халыкта сәламәт яшәү рәвеше алып бару, алкоголь һәм тәмәке тартуны киметүгә караш формалаштыру;
- халыкка профилактик ярдәм оештыруны камилләштерү;
- табиби-гигиена тәрбиясе буенча программаны тормышка ашыру;
- эшчәнлекнең өстенлекле юнәлеше итеп беренчел медицина ярдәме күрсәтүне ныгыту, халыкны дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләрен җайга салу, диспансеризациянең йогынтысын күтәрү.

## Мәдәният

Районда барысы 140 мәдәният учреждениесе эшли. Хисап елында аларның эшчәнлеге иҗат мөмкинлеген үстерүгә, халыкның ялын җайлы, күңелле, уңай оештыруга юнәлдерелде. Бөек Җиңүнең 65 еллыгы, район оешуга 80 ел, Бөтендөнья татар яшьләре һәм татар теле укытучылары корылтае делегатлары катнашында узган Шәһәр көне, Предприятие көннәре кысаларында үтүче фестиваль һәм концертлар халык арасында киң яклау тапты.

Узган ел 4 учреждение республика Хөкүмәте гранты бәйгеләрендә көч сынашты һәм мәдәният бүлеге “Халык иҗаты” номинациясендә җиңеп 900 мең сум, ә Урта Пошалым  китапханәсе “Россия мәдәнияте”

федераль максатчан программасы кысаларында барган проектлар конкурсында катнашып, 500 мең сум грант алуга иреште. Балалар сәнгать мәктәбе укытучысы Фәтхуллина Раилә Динулловна Татарстан Хөкүмәте үткәргән бәйгенең “Һөнәрмәнт” (“Профессионал”) номинациясендә җиңүгә ирешеп, 70 мең сум грант белән бүләкләнде.

Мәдәният учакларының матди–техник нигезен ныгыту зур игътибар үзәгендә тора. Район Мәдәният һәм 40 авыл мәдәният йортында 16 млн. сумлык төзекләндерү эшләре башкарылды. “Мирас” республика программасы ярдәмендә Казиле һәм Ташкичүдәге тарихи мәчетләр яңадан торгызылды. Моннан тыш, 5 млн. сумга музыка кораллары, җиһазлар алынды, сәхнә киемнәре тектерелде.

Район бюджетыннан мәдәниятне үстерүгә 38 млн. сум акча бүлеп бирелде, 2 млн. сум түләүле мәдәният хезмәте күрсәтелде.

Мәдәният өлкәсендә уртача хезмәт хакы 6810 сум тәшкил итә.

***2011 елда мәдәният хезмәткәрләре алдында түбәндәге бурычлар тора:***

- халыкка мәдәният хезмәте күрсәтүнең сыйфатын яхшырту;
- тармакның матди-техник нигезен ныгыту;
- заманча техник чаралар белән җиһазландыруны дәвам итү;
- түләүле хезмәт күрсәтүне киңрәк җәелдерү;
- учреждениеләрдә эшләүчеләрнең һөнәри осталыкларын арттыру, аларның махсус югары белемле булуларына ирешү.

## Спорт һәм яшьләр сәясәте

Физик культура белән даими шөгыльләнүчеләр саны арта. Хәзер алар барлык район халкының 24 процентын тәшкил итә (узган ел 19 процент иде).

Узган ел физкультура һәм спортны үстерүгә 18 млн. сумнан артык акча бүлеп бирелде, 2 млн. сумлык спорт җиһазлары сатып алынды.

Районда 2 балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе, предприятие, оешма һәм мәгариф учреждениеләрендә 150 дән артык спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшли. Аларда 12,5 мең бала һәм өлкәннәр шөгыльләнә. Спорт корылмаларының гомуми саны 172 гә җитте. “Арча” спорт комплексын файдалануга тапшыру район халкына спорт белән актив шөгыльләнергә мөмкинлек тудырды, ел дәверендә 1,5 млн. сумлык түләүле хезмәт күрсәтелде.

Барлык урта мәктәпләрдә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә стандарт спорт заллары бар. Алар укучылар, эштән соң яшьләр һәм өлкәннәр өчен дә хезмәт күрсәтә. Районның җыелма командалары 50 илкүләм һәм республика ярышларында катнашып, шуларның 23 ендә призлы урыннар яуладылар. Җиденче “Сәламәтлек” авыл спартакиадасы нәтиҗәләре буенча безнең район беренче урынга лаек булды.

Районда хәзер спортның 26 төре белән шөгыльләнәләр, шуның 11 төре әле яңа кертелде. Бер ел эчендә 430 разрядлы спортчы һәм өч спорт остасына кандидат әзерләнде.

Ел дәвамында барысы 173 массакүләм спорт чарасы үткәрелде, шуның 7се – республика күләмендә.

“Россия чаңгы юлы”, “Милләтләр кроссы”, “Спортчылар көне”, җәйге һәм кышкы авыл уеннары, предприятие көннәре кысаларында үткәрелүче спартакиадалар шулай ук спорт бәйрәмнәренә әверелделәр. Бу ярышларда Фәнил Гарәфиев, Назыйм Сибәгатов, Марсель Газизов кебек эшмәкәрләрнең оештыручы һәм иганәче буларак катнашулары безне бик куандыра.

Районда спорт белән шөгыльләнү өчен барлык уңайлы шартлар тудырылган, яңа спорт объектлары төзелә, әмма бу гына җитми. Иң беренче чиратта һәр кеше үзе сәламәт булырга омтылырга тиеш. Без бу максатны тормышка ашырырга ярдәм генә итә алабыз.

Яшьләр сәясәте турында берничә сүз. Бүген район халкының 35 проценты 30 яшькә кадәргеләр. Яшьләр белән эшне җанландыру өчен “Яшьләр – районыбыз киләчәге” дигән махсус программа төзелде. “Карлыгач”, “Татарстан варислары” балалар оешмалары уңышлы гына эшли.

“Торак” федераль максатчан программасында катнашып, 18 яшь гаилә 9,4 млн. сум ярдәм алып, үз нигезләрен булдырдылар. Чиратта тагын 81 яшь гаилә тора.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгында яшьләр арасында волонтерлар хәрәкәтенең киң җәелүе зур әһәмияткә ия булды. “Яшьләр агитация поезды” исемле сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау проекты да уңышлы тормышка ашырылды.

***Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә 2011 елда*** гамәлдәге спорт биналарын рациональ файдаланып, физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр санын барлык район халкының 26 проценты дәрәҗәсенә, ә студентлар арасында 50 процентка җиткерү ***бурычы куела***.

## Социаль хезмәт күрсәтү. Опека һәм попечительлек

Узган елда халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре челтәре уңышлы гына эшләде. Махсуслашкан үзәкләрдә 860 гарип тернәкләнү үтте, ел дәвамында 400 өлкән гражданга өйгә барып хезмәт күрсәтелсә, интернат-йортларда – 496 кешегә хезмәт күрсәтелде. Ел эчендә 23 меңнән артык халыкка 73 млн. сумлык ЕДВ һәм субсидияләр түләнде. Күп балалы гаиләләргә социаль патронаж күрсәтелде, хокук бозуларны кисәтү максатыннан эти-әниләр, балигъ булмаганнар һәм имин булмаган гаиләләр белән конкрет эш оештырылды.

Ата-анасыз калган, социаль ярдәмгә мохтаҗ балигъ булмаган һәм ятим балаларның мәнфәгатьләрен яклау максатыннан опека һәм попечительлек хезмәте булдырылды. Ул ашыгыч һәм объектив рәвештә торак, милек, һәм балаларның башка хокук һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итә. Караучысыз калган балигъ булмаган балаларны урнаштыруның өстенлекле формасы булып аларны гаиләгә тәрбиягә бирү тора. Үткән елда шундый 9 бала ачыкланды, алар барысы да тәрбиягә бирелде, 3 бала уллыкка-кызлыкка алынды.

***Социаль яклау өлкәсендә 2011 елга бурычлар:***

1. Бөек Ватан сугышы ветераннарының, шулай ук башка категория ветераннарның, инвалидларның һәм инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча эшне дәвам иттерергә.

2. Социаль яклау органнарының эшен камилләштерергә, йөкләнгән вазифаларны сыйфатлы башкарырга.

3. Хезмәт күрсәтүгә кагылышлы мәсьәләләрне ачыклау максатында үзләренең сайтларын булдырырга.

## Пенсия белән тәэмин итү

Үткән елда гражданнарны пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән чараларның барысы да үз вакытында һәм тулаем үтәлде. 2010 елның 1 гыйнварыннан пенсионерларны матди тәэмин итүне радикаль яхшырту икътисади механизмы уңышлы гына тормышка ашырылды. 1 апрельдән хезмәт һәм дәүләт пенсиясе, ә 1 июльдән дәүләт пенсиясе индексацияләнде. Шуның белән бәйле рәвештә пенсиянең күләме 5247 сумнан 6372 сумга кадәр артты. ЕДВның күләме дә 10 процентка артты. 2010 елда ана капиталы сертификатына ия булучыларның барысы да бу акчалардан кулланды. Хәзер ана капиталы акчаларын торак алуга, төзүгә яки шәхси торак йортны үз көчләре белән реконструкцияләргә тотарга мөмкинчелек туды. 2011 елның 1 февраленнән хезмәт пенсияләре 8,8 процентка үсте, нәтиҗәдә пенсиянең күләме 9655 сум булды.

***2011 елга бурычлар:***

- гражданнарны пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән барлык чаралар комплексын тормышка ашыру;
- клиентлар белән эшләүнең сыйфатын арттыру.

## Җәмәгатьчелек куркынычсызлыгы

Хокук саклау органнарының эффектлы эшләве нәтиҗәсендә халык үзен билгеле бер дәрәҗәдә сакланган итеп тоя. Җинаятьчелеккә каршы көрәшкә юнәлдерелгән хәрәкәт үзенең уңай нәтиҗәсен бирде. 2009 ел белән чагыштырганда теркәлгән җинаятьләр саны 9 процентка азрак (334 җинаять теркәлде). Үтерү, көчләү, талау, куркытып алу кебек җинаятьләр саны кимеде.

Шул ук вакытта аңлы рәвештә сәламәтлеккә зыян салу, складларны, фатирларны, кибетләрне талау, хулиганлык кылу җинаятьләре үсте. 85,6 процент җинаять ачылды (республика буенча бу сан 53,9 процент). Җәмәгатьчелек урыннарында 49 җинаять ясалган, ул 23 процентка, балигъ булмаганнар тарафыннан ясалган җинаятьләр 4 тапкырга (24тән 6га), группалап ясалган җинаятьләр 38 процентка кимеде.

Узган ел 72 юл-транспорт һәлакәте теркәлде, бу 12,5 процентка күбрәк. Анда 14 кеше һәлак булды, шуларның 2се балалар. Юл һәлакәтләренең 41 проценты машина йөртүче, 20 проценты җәяүлеләр гаебе белән ясалды. Җәмәгатьчелек куркынычсызлыгын тәэмин итүгә ел буе игътибар бирелде, бу торак пунктларын, урамнарны яктырту, юлларны, тротуарларны кардан һәм боздан чистарту, биналарны янгын сигнализацияләре белән җиһазлау мәсьәләләренә дә кагыла. Мәгариф, мәдәният, социаль яклау, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә янгынга каршы чараларга шактый акча тотылды. Җәйнең коры килүе безнең өчен чын мәгънәсендә сынау булды. Җитәкчеләр игътибарына шуны җиткерәсем килә: янгын куркынычсызлыгы зур игътибар сорый.

***2011 елда җәмәгатьчелек куркынычсызлыгы өлкәсендә:***

- барлык эшчәнлек өлкәсендә җәмәгатьчелек куркынычсызлыгын һәм хокук тәртибен тәэмин итү;
- хокук саклау органнары эшенең сыйфатын, хокук бозу профилактикасын, гражданнар иминлегенә янауны кисәтү нәтиҗәлелеген күтәрү;
- экстремистлык эшчәнлеге, икътисади җинаятьчелектән куркынычсызлык янауны киметү һәм профилактикалау буенча эш алып бару;

- хокук тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын арттыру һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүдә гражданлык формасын үстерүне ***бурыч итеп куябыз.***

Хөрмәтле депутатлар! 2010 елда ирешкән уңышларыбыз, әлбәттә, ел буе бергәләп тырышып эшләү нәтиҗәсе.

Бүген шушы форсаттан файдаланып, районның социаль-икътисади үсешенә үзегездән өлеш керткәнегез өчен Сезнең барчагызга, Сезнең аша барлык хезмәт коллективларына олы рәхмәтемне җиткерәм.

Алда безне зур эшләр көтә. Моңарчы максатчан юнәлешле эшләп, шактый гына уңышларга ирештек, ләкин тормыш бер урында тормый, ул безнең алга тагын да зуррак һәм җаваплырак бурычлар куя. Вакыт безнең бергә, бердәм булуыбызны таләп итә.

Киләчәктә районыбызның экономикасын тагын да үстерү, ныгыту, халкыбызның тормыш-көнкүреш шартларын тагын да яхшырту буенча көчебезне кызганмыйча, булган тәҗрибәләребезне һәм белемебезне тулысынча файдаланып чын күңелдән тырышып хезмәт итәрбез дигән теләктә калам.

Чыгышымны тәмамлап, Сезне максатчан эшкә чакырып калам. Исән-сау булыйк, бәхет һәм уңышлар юлдаш булсын.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.